**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ 2 НЧЕ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Петровка авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге составына керүче Петровка авылы**

**Петровка авылы, 2025 елның «21» ноябре**
**Үзәк ур., 8 йорт (мәдәният йорты) 11 СЧ.00мин.**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33 номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Бөгелмә муниципаль районының «Петровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Петровка авылы торак пунктындагы гражданнар җыены

карар кылды:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Петровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Петровка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Җыелган акчаларны «Петровка авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең Петровка авылында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (Иске плафоннарны 15 данә күләмендә яңаларына алмаштыру) ремонтлауга юнәлтергә."

**Гражданнар җыенында рәислек итүче-**
**" Петровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы О.Н. Конычев**